ГЛАВА
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.10.2022 г. Агрыз № 91

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча иҗтимагый фикер алышуларны билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 24 статьялары, «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2018 елның 27 июнендәге 28-2 номерлы карары белән расланган «Гавами тыңлауларны, җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында» нигезләмә нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлегенең генераль планын килештерү проекты буенча иҗтимагый фикер алышуларны (алга таба - проект)билгеләргә

2. Билгеләргә:

2.1. Җәмәгать фикер алышуларын үткәрү вакыты – 2022 елның 28 октябреннән 2022 елның 28 ноябренә кадәр;

2.2. планлаштыру проектын һәм сызыклы объектны межанлау проектын бастыру өчен рәсми сайт – http://agryz.tatarstan.ru (Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайты)

2.3 Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлеге башкарма комитеты.

3. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручыга:

3.1. Әлеге карарны 2022 елның 24 октябрендә Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http://agryz.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлеге җирле үзидарә органнары бинасында урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштырырга;

3.2. Иҗтимагый фикер алышулар башлану турында хәбәрнамәне Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында http://agryz.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru, шулай ук Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының мәгълүмат стендларына урнаштырырга;

3.3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный бор авыл җирлеге башкарма комитетының административ бинасының беренче катында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный бор авыл җирлеге Генераль планын килештерү проекты буенча экспозиция ачу, шулай ук килүчеләрне 2022 елның 28 октябреннән 2022 елның 28 ноябренә кадәр чорга экспозиция белән таныштыру мөмкинлеген тәэмин итергә.

3.4. 2022 елның 28 октябреннән 2022 елның 28 ноябренә кадәрге чорда әлеге проект буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне идентификация узган килүчеләрдән кабул итәргә:

- язма формада Татарстан Республикасы, Красный Бор авыл җирлеге, Красный бор авылы, Маркин ур., 35 йорт адресы буенча

- проект экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу китабына язу аша: Татарстан Республикасы, Красный Бор авыл җирлеге, Красный бор авылы, Маркин ур., 35 йорт адресы буенча.

3.5. Проект буенча фикер алышу нәтиҗәләре буенча иҗтимагый фикер алышулар протоколын һәм иҗтимагый фикер алышуларның нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә.

3.6. 2022 елның 28 ноябрендә "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында http://agryz.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru Иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре турында бәяләмә бастырырга

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе А. Э. Акбашевка йөкләргә.

**А.Р. ВӘЛИЕВ**

Башкаручы:
Л.С. Барекова